Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ АПРЕЛЬ * 2021 * КАЗАН

4



Сергей АНДРИАНОВ

Алмаз ХӘМЗИН

ТАТАР СҮЗЕ

Татар сүзе!
Кемнәргәдер ул – куркыныч,
Күпләргә – җан азыгы!
Чын татарга – Ана теле,
Маңкортка – гүр газабы!

Татар сүзе!
Таңнарда ул нур аттыра.
Кичләрдә җыр тарата.
Көндезләрен таныштыра,
Төннәрен кавыштыра!

Татар сүзе!
Дәверләрдә сыналган ул,
Гасырларда кыйналган,
Өзгәләнгән һәм туралган,
Таланган, исән калган.

Татар сүзе!
Чыныккан ул яулар кичеп,
Ныгыган, сабак алган.
Һәр сынау аңа көч биргән,
Җиңеп кайткан, данланган!

Татар сүзе!
Кол Галиләр телендә ул,
Кол Шәрифләр телендә!
Явыз дошман башын чабып,
Өзсә дә бар, бүген дә!


Татар сүзе!
Мөхәммәдъяр элеп алган,
Алар салган бу телне.
Бөек Тукай дәвам итеп,
Коткарган матур гамьне!

Татар сүзе!
Ибраһимовлар сүзе ул,
Такташ, Туфаннар сүзе.
Сатылмаган Усмановлар,
Чыкса да ике күзе.

Татар сүзе!
Җәлилләр һәм җәлилчеләр
Фашист йорты эчендә,
Шигырь булып, җырга күчеп,
Илгә кайтты үлмичә!

Татар сүзе!
Шундый сүз ул, шундый сүз!
Яшәү гамьсез, аны белмичә!
Татар сүзе берәгәйле –
Дөрес, туры, минемчә!

Михаил ЛАРИЧЕВ



ШОМБАЙ
болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Мин улымны бала чагыннан ук намуслы булырга – алдашмаска, гайбәт сөйләмәскә, бөтен нәрсәне турыдан-туры әйтергә өйрәттем. Ул саф күңелле, шәп егет булып үсте. Армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң институт бетереп, эшкә урнашты. Күптән түгел ул башлыгы белән сүзгә килгән. Хаклык улым ягында булып, коллектив аның яклы булса да, башлык «дөнья болгатучыны» кыскартырга карар кылган. Имеш, оешма кризис кичерә, һәм штатны «кысарга» кирәк. Ә үзе шундук аның урынына үз кешесен утыртып куйган. «Менә, ә син көч хаклык ягында, диган идең», – диде улым бу хәлләрдән соң...

И. К-ОВ.

ТҮБӘН КАМА

– Көч элеккечә хаклык ягында, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Ләкин хаклык көчлеләр кулында...**

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Нәрсәдер дөрес эшләми икән, борчылма. Әгәр бөтен нәрсә дә тиешенчә эшләсә, син эшсез утырыр идең.

Мөһим кәгазьләрнең мөһимлеге аларны югалтып эзли башлагач кына ачыклана.

Һәр оешмада эшне ничек оештырырга кирәклеген белгән кеше табыла. Аны, гадәттә, эштән азат итәләр.

Замана технологияләре могҗизасы: ташланган сыра банкасы җирдә мәңге ята ала, ә кыйммәтле затлы автомобиль икеөч елдан ук тутыга башлый.

Әгәр дә катлаулы мәсьәлә белән интегәсез икән, аны ялкауга тапшырыгыз. Ул аны иң тиз һәм җиңел юл белән эшләячәк.


Компьютер беркайчан да кешене алыштыра алмаячак. Чөнки ул эштән аерылып, сәгатьләр буе телефоннан сөйләшеп утыра белми.

Бәлки, синең тормыштагы төп урының – башкалар өчен тере кисәтү булудыр?

(тормыш белгечләре мәҗлесендә язып алынды)



Валерий ТАРАСЕНКО



Илдар НӘФИЕВ

ИНТЕР-НЕТ КАРАКЛАРЫ

Кешеләрдәге ачыклык һәм беркатлылыкны бигрәк тә мошенниклар югары бәяли. Бөтен дөньяга күпме кычкырма, алданганнар армиясе артканнан-арта бара. Бар нәрсәне белеп торучы статистика әһелләре белдерүенчә, Татарстанда узган ел эчендә банк карталарыннан, интернет аша урлаулар саны 55 процентка арткан. Хокук саклау органнарының моңа әллә ни исе китми – ә нәрсә, цифрага кучү хикмәте! Хәзер гражданнарның җыйган акчалары элеккечә матрас астында ятмый, ә банк карталарында саклана. Ә караклар күршедә түгел, ә бөтен Җир шары буенча яши, һәм аларның куллары сезнең счётка дөньяның теләсә кайсы ноктасыннан җитә ала. Дөнья гына түгел, мошенниклар да глобальләшү кичерә!

Чаллыда яшәүче слесарь П. бу статистика белән таныш булмагандыр, күрәсең. Шуңа күрә ул банктан шалтыратуны бик җиңел һәм ышанып кабул итә. Аңа, счётындагы акчалары юкка чыкмасын өчен, аларны резерв счётына күчерергә тәкъдим итәләр. Тир түгеп табылган 240 мең җиңел генә чит кеше кесәсенә күчә. Әмма бу хәлнең гомуми статистикага керүе бик шикле. Закон сакчылары үзләре әйтүенчә, мондый очракларның уннан бере генә ачыла.

Ә менә чираттагы вакыйга күпне күргән полицейскийларны да аптырашта калдырган. Шул ук Чаллыда мошенниклар бер пенсионер хатынның картасыннан акчасын үзләренә күчерү өстенә бичараны кредит алырга да күндергәннәр. Кредитка алынган акча да караклар кесәсенә күчеп утырган. Нәтиҗәдә, ханым ярты миллион сумнан колак каккан. Өстәвенә, әле яңадан шалтыратып, аны алдаганнарын һәм яшәү өчен счётында биш мең калдырулары турында хәбәр иткәннәр. Тагын шуны әйтергә кирәк, ул ышанучан кешеләрне төп башына утыртучы "үзәк"ләрнең күбесе чәнечкеле чыбык артында урнашкан, ә оператор сыйфатында эшләүче "олы җанлы" караклар – шунда срокларын уздыручылар.

Күңел кылларын тибрәндергеч бу вакыйга Азнакайда булган. 60 яшьлек абзый бөтендөнья челтәрендә гүзәл кыз белән танышкан. Туташ монда Африкадан килгән, һәм хәзерге вакытта матди ярдәмгә мохтаҗ икән. Аның кара континентта яшәүче әтисенең счётында 6 миллион доллар ята, һәм аларны үзенә күчерер өчен чибәркәйгә... бераз акча кирәк икән. Азнакай Мәҗнүне, яше турында онытып, интернет мәгъшукасына ярдәмгә ташлана, һәм йөрәк дустына 524 мең сум күчерә. Бөтенләй үк бушлай түгел, әлбәттә – әлеге алты миллионның 10 проценты бәрабәренә. Рәхмәт йөзеннән, кызыкай элемтәгә чыкмый башлый. Абзыйга бәхет елмая: кызны, дөресрәге, егетне, тиз арада табалар. Ул Нигериядә яшәүче 24 яшьлек ир кеше булып чыга.

Мошенниклар кармагына дөньядан бөтенләй артта калган мокытлар гына кабып тора дисәк, бу дөрес булмас иде. Мәсәлән, күптән түгел Санкт-Петербургта генерал хәтле генералны төп башына утыртканнар. Эчке эшләр министрлыгы департаменты башлыгының урынбасары счётыннан 612 мең сум юкка чыккан. Лампаслы ыштан иясе сүзләренә караганда, ул "психологик тәэсиргә бирелгән", һәм "банкның иминлек хезмәтенә" булган өч картасының да мәгълүматларын тапшырган. Мундирга тап төшермәс өчен, эшкә төньяк мәркәзнең иң шәп тикшерүчеләре җигелгән. Махсус оештырылган профессионаллар төркеме дүрт ай эчендә җинаятьченең эзенә төшкән.

Гади кеше тикшерү эшләренең мондый тизлекләр белән баруы турында хыяллана гына ала, әлбәттә. Гадәттә, эш гариза кабул ителгән чакта ук туктап кала. Ачылмаслыгы алдан ук билгеле булган "баш бәласе" кемгә кирәк булсын ди? Ә мондый хәлдә калмас өчен, хокук саклау органнары шушы кагыйдәне истә тотарга тәкъдим итә: банк хезмәткәрләре беркайчан да беркемгә дә үзләре шалтыратмыйлар. Әгәр шик туса, алар счёт иясеннән башка блокировка ясый.

Кыскасы, соңыннан үкенмәс өчен, уяу булыгыз. Үзегезнең ачык күңелле, беркатлы булуыгыздан мошенникларга файдаланырга ирек бирмәгез.

Людмила САФИУЛЛИНА



Вячеслав ШИЛОВ



Валентин ДУБИНИН



Виктор ФЁДОРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



• • •

Кыз өенә бер егетне алып кайта да, әнисе белән таныштыра:

– Таныш бул, бу минем булачак беренче ирем!

• • •

Хатыны – иренә:

– Комсызланып, үткән-киткән хатыннарны карап утырма инде!

– Мин бит күз белән генә.

– Алайса авызыңны чапылдатма, ичмасам!

• • •

Яхшы табиб-невропатологныкы барысы да нервыдан: йортлары да, машинасы да, бакчасы да...

• • •

– Безнең яңа күршеләребез шундый әйбәтләр: ире хатынын гел үбә, коча, ягымлы сүзләр әйтә. Нигә син шулай эшләмисең?

– Мин бит аның белән таныш та түгел әле!

• • •

Робин Гудтан аермалы буларак, безнең салым инспекциясе ярлылардан акча җыя да, байларга бирә.

• • •

Медицинаның әхлакый ягыннан чыгып, үлгән кешегә "үлде" дигән диагноз кую – "алга таба дәвалануга мохтаҗ түгел" дигәнгә алыштырыла.

• • •

Хәзерге буын кешеләре безгә караганда акыллырак. Чыннан да, моның белән килешмәү мөмкин түгел. Ләкин шундый бер хакыйкатькә игътибар итәргә кирәк – элек автомобиль белән идарә итү инструкциясенә ничек итеп клапан аралыкларын көйләү турында язалар иде, ә хәзер аккумулятор сыекчасын эчәргә ярамый икәнен искәртәләр.

• • •

Элек мин караңгылыктан курка идем, ә миңа кичә квитанцияләр китерделәр. Хәзер инде уттан, судан һәм җылыдан куркам. Әле тагын чүптән дә курка башладым.

• • •

– Аңламассың замананы... Барысы да татуировка белән – кайсы утырган, кайсы утырмыйча да...





Күптән түгел Казанда "Татарская хитрость" ("Татар хәйләсе") дип исемләнгән мәзәкләр китабы басылып чыкты. Безнең халык тормышта очраган тискәре күренешләргә, үз гореф-гадәтләренә, гаделлеккә каршы килгән вакыйгаларга беркайчан да битараф калмаган. Һәм ул борынгыдан килгән җор телле гыйбарәләр хәзер дә яши. Китапта тупланган мәзәкләрнең зур гына өлеше бөтенебезгә таныш төрки фольклор каһарманы Хуҗа Насретдингә багышланган. Сезгә аларның берничәсен тәкъдим итәбез.

ГАДЕЛ БУЛУ

Хуҗа базарда йөргән чакта акча тулы янчык тапкан. Аны өскә күтәреп, ул халыкка мөрәҗәгать иткән:

– Кайсыгыз акча югалтты?

Халык арасыннан бер хәерче чыккан.

– Бу минем акчам! — дигән ул.

Шунда ук икенче яктан бай килеп чыккан:

– Юк, бу янчык минеке!

Хуҗа байга карый һәм сорый:

– Әйт әле, бу янчык чынлап та синекеме?

Бай шатланып җавап биргән:

– Әйе, әйе, Хуҗа, ул чынлап та минеке.

Хуҗа тагын бер кат байга һәм хәерчегә караган да, болай дигән:

– Ярый, бай, ал үз әйбереңне! Янчык синеке, ә акча аныкы, – һәм янчыкны байга, ә акчаны хәерчегә тоттырган.

ИШӘК ӨСТЕНДӘ

Хуҗа ишәгенә атланып базарга китеп барганда аның артыннан ат менгән бер бай килеп җиткән. Ул, Хуҗаны хурламакчы булып:

– Йә, ишәк өстендә бару ничек, әйбәтме? – дип сораган.

– Атка атланган ишәккә караганда, акыллы баш булып, ишәккә атланып йөрү күңеллерәк, – дип җавап кайтарган Хуҗа.

КЕМ БӨЕГРӘК?

Бервакытны Хуҗа Насретдиннән:

– Әйт әле, Хуҗа, патшамы, әллә крестьянмы, кайсы бөегрәк? – дип сораганнар.

– Юләр сорау, – дигән Хуҗа, – билгеле, крестьян. Әгәр крестьян иген икмәсә, барлык патшалар да ачтан үлеп бетәрләр иде, – дигән.

НӘРСӘ ФАЙДАЛЫРАК?

Хуҗадан сораганнар:

– Әйт әле, синеңчә, нәрсә файдалырак: Кояшмы, әллә Аймы?

Хуҗа:

– Ай, — дип җавап биргән.

– Нигә?

– Чөнки Кояш көндез, болай да якты вакытта яктырта, ә Ай төнлә, караңгы вакытта.

ЕГЕТ СҮЗЕ

– Сиңа ничә яшь? – дип сораганнар берзаман Хуҗадан.

Ул, кырык, дип җавап биргән. Биш ел үткәч, аңа шул ук сорауны биргәннәр.


– Кырык яшь, – дип җавап биргән Хуҗа.

– Ничек инде, һаман кырык та кырык? Син бит биш ел элек тә кырык дип әйткән идең, – дигәннәр күршеләре.

– Мин әйткән сүземнән беркайчан да кире кайтмыйм. Егет сүзе бер булыр! – дип җавап биргән Хуҗа.







Валерий ТАРАСЕНКО



Илдар НӘФИЕВ



Ринат БӘШИРОВ

Гүзәл НӘБИУЛЛИНА



Очрашу

Алар очраклы гына автобус тукталышында очраштылар. Язның әле башы гына. Кешеләргә битлексез урамга чыгарга ярамаган чак. Иң беренче итеп ул аның моңсу күзләренә игътибар итте. Һәм кыюсыз гына янына килеп, юаткан сыман эндәште:

– Матуркай, нигә сез күңелсез?

– Ирем белән бераз әйткәләшеп алдык, җитмәсә, автобус та озак көттерә.

Кызга аның тавышы бик тә таныш тоелды. Әйтерсең лә ул туганын очратты.

– Беләсегез килсә, минем исемем Рамил, – диде егет чын исемен әйтергә теләмичә. Очраклы очрашу-танышулар беркемгә дә дөрес сәйләүне бурыч итеп куймый бит.

– Тәнзилә, – дип әйтте үзен кыз. Шулай ук үз исемен яшереп. Шулчак автобус та килеп җитте, аңа китәргә кирәк иде.

– Тәнзиләкәй, тагын кайчан очрашабыз? Әйдә, буген кич, шушы урында.

Рамил көне буе тынгысыз аны көтте: килерме, юкмы? Кызның күзен генә түгел, йөзенбитен күрәсе килә иде аның. Ләкин битлек киеп йөрүне һич бозарга ярамый – закон.

Менә кич тә җитте. Алар очраштылар. Кафе, театрлар эшләми, шуңа күрә урамда йөрделәр. Кичке һаваның рәхәтлеген тоеп, ашыкмый гына. Култыклашкан да булдылар. Сөйләшә торгач, уртак фикерләре дә барлыгы беленде.

– Тәнзиләкәй, – диде ул кисәк кенә аңа карап, – Нишләп ирегез белән ачуланыштыгыз?

– Мин аны сирәк күрәм. Үкенечле. Иртүк чыгып китә, ә мин йоклап калам. Кайта бик соң – төнлә, ул чагында инде йоклаган булам. Ә син үзең, Рамил? Хатының бармы?

– Әйе, мин дә аның белән бик үк дус яшәмим. Аны гел йоклаган килеш күрәм. Өйгә кайчан кайтсам да, ул һаман йоклый.

Саубуллашканда, алар тагын очрашырга сүз куештылар. Телефоннар белән алышмаска булдылар. Нәрсә килеп чыкмас...

Шулай җәй үтте. Алар бер-берсенә шулхәтле күнекте, гел очрашуны көтә иделәр. Битлектә йөрүне һаман бетермиләр, ләкин бу мәсьәлә аларны борчымый. Алар урамда сөйләшү рәхәтенә назландылар. Моңа битлек комачауламады.

Беркөнне Тәнзилә Рамилгә ирен куып чыгаруы турында хәбәр итте.

Рамил дә аңа:

– Беләсеңме, мин дә хатыннан киттем. Бәлки, безгә кавышыргадыр? Берәр фатир табып, бергә яшәрбез.

Тәнзилә шатлыгыннан риза булды. Күп тә үтмәде, фатирын да таптылар. Менә ул ике якын җанның күптән көтелгән назланулары. Үз фатирларында, үз ирекләрендә, саф мәхәббәт кочагында! Битлекләр читкә очты!..

Без мизгел... катып калдылар... элеккеге ир белән хатын...



Алмаз ХӘМЗИН

КЫЧКЫРТЫП АЛДЫЙЛАР

Әйтмичә, кисәтмичә дә
Яз килә – рәхмәт аңа!
Бөтен эшен үти, чөнки –
Калган эшкә кар ява!..

Юа үткән кыштан калган
Җыен каралганны ул.
Яшел төскә керә җиһан,
Сафлана, нурлана ул!

Күңелләргә яшәү дәрте
Кузгала язлар килгәч.
Җыр бөркелә табигатькә –
Сыерчык, тургай күргәч.

Тик бер нәрсә алып килми –
Яз саен заргып көтәм:
"Күкеләре" һаман алдый,
Парламентлары белән!









АЛДЫНГЫЛАР САФЫНДА

Ачыкланган ришвәтчелек очракларының саннары буенча беренче урында Мәскәү тора. Мактаулы икенче урында – Татарстан. Аннан соң Ставрополь крае, Мәскәү өлкәсе һәм Башкортстан бара. Коррупция күрсәткечләре буенча иң артта калган өлкәләр – Чукотка, Еврей автономияле өлкәсе һәм Мари Иле. Белгечләр әйтүенчә, мондый нәтиҗәләр табигый хәл: гадәттә, күрсәткечләр буенча һәрвакыт акча күп тупланган һәм ришвәтчелек эшләре актив рәвештә ачылып барган өлкәләр алгы сафка чыга.

МОГҖИЗАЛЫ ӘВЕРЕЛҮ

Теләче районының Айдар җирлеге депутаты Дмитрий Чернов җиңел генә халык вәкиленнән шиклегә әверелгән. Хокук сакчылары белдерүенчә, депутат берничә тапкыр бергә яшәгән хатынынннан акча урлаган. Башта ул аның картасыннан 7 мең алган, аннан соң мәгъшукасының сумкасында 135 мең сум табып, анысын да үзләштергән, ә соңрак аяк киеме тартмасында яшереп куйган 100 меңен дә тапкан. Депутатлыктан башка, аның бүтән керем чыганаклары булмаган.

КӨТЕЛМӘГӘН ДИАГНОЗ

Чаллыда яшәүче яшь егет Ватан алдындагы бурычын үтәргә теләмәгән һәм ярдәм сорап танышына мөрәҗәгать иткән. Тегесе 100 меңгә аны армиядән алып калырга сүз биргән – призывникта ашказаны җәрәхәте "табарга" тиеш булганнар. Егет тиешле акчаны тапшырган да медицина комиссиясе узган. Әмма көтелмәгәндә анда чын җәрәхәт табылган. Призывник "ярдәмче"гә киткән, ләкин тегесе, бу авыру белән хәрби хезмәттән азат ителмиләр, дип белдергән һәм эшне ахырына җиткерү өчен тагын акча сораган. Шунда гына бичара егет хокук органнарына мөрәҗәгать иткән.

ЭРОТИКА КОРБАННАРЫ

Казанда икенче тапкыр бер үк "Эролайф" исемле секс-шопны талаганнар. Шунысы кызык – бу "нәфис" эшне шул ук егет белән кыз башкарган. Беренче урлау узган елның декабрендә булган, ул чакта алар тартмадагы резин курчакны һәм интим уеннар җайланмасын эләктереп чыккан булганнар. Бу юлы исә эротика сөюче яшьләр кибеттән барлыгы 8 мең сумлык "өлкәннәр өчен уенчыклар" алып чыкканнар. Егет белән кызның кыюлыклары чиктән ашкан: алар, яшеренмичә, урлашырга бер үк киемнән йөргәннәр.

Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Александр БРЮХАНОВ

Тормыш хәлләре

Олигарх Мотыйгуллинның гаилә тормышы берничек тә рәткә керми иде. Инде җиденче хатыны, акчасының яртысын үзенә калдырып, ташлап китәргә йөри. Кич саен өйдә кадак та какканың юк, бергәләшеп елына өч тапкыр гына ял итәбез, дип кычкыра. Анысы да ярдәмчеләр, сакчылар, секретарь кызлар белән генә; өйгә акча алып кайтканың юк, бөтен тапканыңны ниндидер оффшорларга күчереп барасың, имеш...

Кыскасы, туйды Мотыйгуллин мондый тормыштан. Тормышны яңабаштан башларга кирәк иде.

Вак сәүдәгәр Өтекшин дә гаилә тормышын һич тә җайга сала алмады. Хатыны инде егерме ел буе Мотыйгуллиннардан начаррак яшибез, дип колак итен ашый, үзләренең ларёкларыннан алган азык-төлеккә карый да алмый, ә ул алып кайткан вак акчалар белән кеше янына чыгу оят. Имеш, ире берөзлексез яшь сатучыларны алыштырып тора, дачага йөрми, өйдә ял көннәрендә генә була, һәм моның чиге күренми...

Туйды Өтекшин бу хәлдән... Күптән аерылышырга теләгән иде инде, һаман, ничектер, барып чыкмый...

Ә элекке инженер, хәзер өендә эшсез утыручы Гыйльмуллинның хатыны, аерылган килеш тә, көн саен телефоннан теңкәсенә тия иде. Кадак кагудан башка кулыңнан бер эш тә килми, акча таба белмисең, ә синең кебек булдыксызлар дөнья тулы, имеш...

Ә менә физкультура институты студенты Айгыршин бүлмәсенә көн саен яңа хатын алып кайта иде – йә олигарх Мотыйгуллинның хатынын, йә ларёк сәүдәгәре Өтекшинныкын, кайчагында эшсез инженер Гыйльмуллинның чибәрен... Төн буе аларның моң-зарын тыңлап ятканнан соң, иртән тормышны өр-яңадан башлау кирәклеген аңлап уяна ул...


Тик тормышта бернәрсә дә үзгәрми иде. Чөнки эволюция юлы революциягә караганда, күпкә дөресрәк бит...

Игорь КИЙКО









• • •

Табиб авыруга аракыдан баш тартып, тик сөт кенә эчәргә тәкъдим иткән. Авыру сукрана-сукрана өч көн рәттән сөт эчкән дә, дүртенче көнне табибка килеп:

– Хәзер мин имчәк балаларының ни өчен бертуктаусыз көйсезләнүләрен һәм елауларын аңладым, – дигән.



СҮЗ ИЯРӘ – СҮЗ

- Сәламәтлек саклау министрлыгы кисәтә: виртуаль тормыш белән мавыгу геморрой китереп чыгара!
- Медицинаны «оптимизацияләү» тагын берничә ел дәвам итсә, сәүдә үзәкләрендә вакцинация гына түгел, ә төрле хирургия операцияләре дә ясалачак.
- Ковидка каршы көрәштә иң зур уңышларга статистика иреште.
- Түләүле клиникаларда вак бетчәләр дә хроник авыруларга әйләнә.
- Безнең хастаханәләрдә йөрергә нинди сәламәтлек кирәк!
- Бөтен дарулардан да ул «Доктор» колбасасын артык күрә иде.
- Хәзер шулкадәр дарулар барлыкка килде ки, кеше организмы яңа авырулар китереп чыгарырга өлгерә алмый.

Абау!

БЕЛГОРОД КВЕСТЫ

Белгород өлкәсе губернаторы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Вячеслав Гладков үз-үзенә кабул итүгә язылала алмаган. Эксперимент өчен, башлык администрация телефоннарына шалтыраткан, тик аңа җавап бирмәгәннәр. Киңәшмәдә Гладков «буран уйнаткан» һәм аңлатма язуны таләп иткән. Ул бу хәлләрне Белгород квесты дип атаган һәм гражданнарның инде өч ай буе губернаторга шәхси сораулар буенча языла алмавы турында белдергән.

ГОМУМИ КИРӘК-ЯРАКЛАР


Аерылышканнан соң, Чиләбедәге ир белән хатын пластик операциягә алынган кредитны бүлә алмыйлар. Ире хатынын үзгәртергә тели һәм күкрәген зурайту өчен, хирург пычагы астына ятарга күндергән. Бу максат өчен ул 200 мең сумлык кредит алган. Әмма яңарыш ярдәм итмәгән – ир белән хатын барыбер аерылыша. Ире кредитны ялгызы гына түләүдән баш тарткан, чөнки тулыландырылган күкрәк тулысынча хатыны карамагында калган бит. Кредитны урталай бүлү мөмкинлеге бар, чөнки ул уртак гаилә ихтыяҗларына алынган булган.

ЮМАРТ БҮЛӘК

Ленинград өлкәсе хәрби комиссариаты хатын-кызларга үзенчәлекле бүләк ясаган. Хәрбиләр, инстаграмда видеодагы хезмәт итүдән качып яткан элеккеге егетләренең аккаунтларын сылтамада калдырырга тәкъдим иткәннәр. Күп кенә хатын-кызлар, хәрби комиссариатның чакыруын шатланып кабул иткәннәр һәм «качкын»нарның мәгълүматларын дөньяга чыгарганнар.

АК ДИСКРИМИНАЦИЯ

Британия полициясе хезмәткәре Мэттью Парр үзенә карата раса дискриминациясенә түзәргә теләмәгән. Ул кара тәнле коллегасы, бер үк урында эшләүгә карамастан, хезмәт хакын аңа караганда күбрәк алган. Британия хакимияте дискриминациядә гаепләүне кире каккан. Хәзер полицейский вазыйфалары өчен азрак түләнә, дип белдергән, хезмәттәшенең хезмәт хакының артыграк булуын аның эшкә аннан алданрак урнашуы белән аңлаткан. «Төсле» бәхәскә ахыргы ноктаны суд куячак.



Михаил ЛАРИЧЕВ



Виктор ФЁДОРОВ



Ринат АБЗАЛОВ

Мирзаһит тормышыннан

БИЧАРА ЮЗИМ

Авылда бәрәңгене күрше-күлән һәм туган-тумача белән кумәкләшеп утырта: шулай иткәч эш тиз һәм күңелле бара.

Бу юлы беренче итеп Юзимгә утыртырга булдылар. Хуҗа кеше барысына да көрәкләр, чиләкләр өләшеп чыкты, һәм эш кайный башлады. Әгәр берәрсенең чиләгендә бәрәңге бетсә, Юзим йөгереп килеп өсти, ә кемнеңдер эчәсе килсә, су китереп бирә иде. Бер сәгать дигәндә бәрәңге утыртылып та бетте.

Аннан соң барысы да бергәләшеп Ниязларга киттеләр. Уен-көлке, шаян сүзләр белән эш бик тиз барды. Ләкин менә Юзим, нишләптер, акрын кыймылдады.

– Нәрсә булды? Бәтәрәең утырдымы әллә? – дип сорады Нияз.

– Көрәгең әллә нинди шунда ... үтмәс, начар казый! – дип җавап бирде акланган сыман Юзим. Аптырагач, аның көрәген алып, буразна сызу өчен маркер тоттырдылар. Ләкин бу да аңа дәрт өстәмәде – эшен анннан-моннан башкарып, башкаларны тоткарлап барды.


– Маркерыгыз ниндидер кәкре, эшләп булмый! – дип сукранды Юзим.

Эш тәмамлангач, Ниязның хатыны ишегалдында ашъяулык җәеп, анда итле борчак ашы, пешкән бәрәңге, яңа сауган сөт китереп куйды. Ниһаять Юзимгә җан керде: ул ашын да, бәрәңгесен дә күпләп ашады, аннан соң бер банка сөт тә эчеп куйды.

Мирзаһит түзмәде:

– Көне буе интекте бит, бичара... Ниһаять аңа эшли торган кашык бирделәр! – диде ул. Халык тәгәрәп көлде.

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



Максим СМАГИН

БЕР АЙДАГЫ ИКЕ ХАТИРӘ

Минә апрель ае да килеп җитте. Ул ай нәрсә белән истәлекле, беләсезме? Һәр кешегә үзенеке белән, әлбәттә. Әмма миңа бала чагым искә төшә.

Мәктәптә укыган вакытлар. Безгә нәрсә инде? Апрельдә Ленин бабайның туган көне. Ул бәйрәмгә класс белән әзерләнәбез. Җырлар өйрәнәбез. Өченче сыйныфта укыганда пионерга алдылар. Әле дә хәтеремдә, нәкъ Ленин туган көне – 22 апрельдә. Көне бик җылы булмаса да, кояш балкый иде, урамда карлар эри. Мәктәптән кайтканда мин пәлтәмне чишеп кайттым. Барысы да күрсен, белсен: мине бүген пионерга алдылар. Мин пионер булдым! Кызыл галстугым җилдә җилферди. Ник бер кеше игътибар итсен? Ник бер кеше котласын: "Пионер да булдыңмыни инде? Менә бит, шундый зур исемгә дә лаек булгансың", – дип.

Ярар, анысы аларның эше. Минем өчен бу бик зур бәйрәм. Мин – пионер. Горурланып, башымны югары күтәреп кайтам. Кәеф күтәренке. Үзебезнең урамга кергәндә күрше әби каршыма очрады. Аның шундый кызык гадәте бар иде – "Исәнмесез" дисәң, "Бәк әйбәт, үзең әйбәт булсаң", дия торган. Бу юлы мин исәнләшергә дә өлгермәдем, ул беренче дәште: "Әй балам, шулай зур булдыңмыни? Пионерга алганнар икән. Алай... Маладис. Бәхетле бул!" – дип куйды. Миңа канатлар үскәндәй тоелды. Нинди рәхәт, мин – пионер!

Шулай ук Ленин бабай белән бәйләнгән нәрсәне сөйләп китәсем килә...

Безнең туганыбыз Мәскәүгә барган. Кайткач, безгә кунакка килеп, аның матурлыгын, халыкның күплеген сөйләп утырды.

– Башкала хәтле башкаланы күреп, мавзолейга керми кайтып булмый бит инде, – ди. – Аннары синең анда булганыңа кем ышансын.

Мавзолейга буш кул белән генә керергә рөхсәт ителгәнен кем белгән? Кулымда сумка. Чират җитте. Нишләргә инде? Кире китәсем килми... Юбка астына тыктым сумкамны, пута белән ныграк бәйләп, кереп киттем.


Мавзолейда ут сыек кына янып тора. Караңгырак дип әйтсәң, дөресрәк булыр. Аска баскыч. Тик караңгыда аяк астында нәрсә булганын каян күрәсең инде? Атлавым булды, сөртенеп егылдым да, юбка астындагы сумкам шапылдап килеп төште. И хурландым инде. Сакчылар шикләнеп миңа карадылар. Аннары, "бу авыл апае гына икән, беренче керүедер", дигән сыман, ,иркенләп сулап куйдылар.

Менә шулай, мин Ленин бабайны күреп кайттым... – дип тәгәлләгән иде ул үзенең хикәясен.

Әйе, совет вакытында үскәннәргә Ленин исеме изге исем иде. Апрель ае килгән саен, шул хатирәләр исемә төшә.

Гүзәл НӘБИУЛЛИНА

Пётр КУЛИНИЧ, «Чаян» № 11, 1989



Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 7, 1996





• • •

Пенсия фонды хезмәткәре әбидән сорый:

– Әбекәй, сезнең шәхси кабинетыгыз бармы?

– Син, нәрсә, кызым? Минем фатирым бер генә бүлмәле.

• • •

Статистика буенча, 9 нчы класста укучы кызларның карар җирләре бар, ә 11 дәгеләрнең инде, нәрсә сөйләрлекләре дә җитәрлек.

• • •

– Әйе, заманалар үзгәрә... Элек “миңа гадәттәгечә!” дип керә идем кафега.

– Ә хәзер?

– Ә хәзер – аптекага.

• • •

Судья:

– Сез гаеплеме, юкмы?

– Монысын үзегез ачыклагыз – сез шуның өчен акча аласыз бит.

• • •

Табиб – авыру ханымга:

– Авызыгызны шулкадәр ачмагыз.

– Тамагымны карарга теләдегез бит.

– Ашказаныгызны кереп карыйм димәдем ләбаса!

• • •

– Сез исерек ич, – ди автоинспектор шофёрга.

– Гафу итегез, машинаны аек килеш йөртә алмыйм – кулларым калтырый...

• • •

Һәрвакыт шундый яңалыклар ишетеп торам – беркатлы әби, алданып, жуликларга 3 миллион сум күчергән. Аптырап куям, кайдан килгән бу алданучыларга шулхәтле акча?

• • •

– Нәрсә уйлап утырасың?

– Кызык, беренче булып нәрсә кыйбатланган икән: тавыкмы, әллә йомыркамы?

• • •

Сәлам! Нигә бик кәефсез?

– Менә эшкә урнашырга уйлаган идем – алмыйлар, син карт инде, диләр. Ә пенсия бирмиләр, чөнки әле яшь...









ӨЧ ТИЕН ӨЧЕН ҖАННЫ КОРТАЛАР...

Кадерле редакция! Әгәр сезгә дәүләт төкереп карый дип уйласагыз, бер тапкыр булса да салым түләмәгез әле. Бу шаярып әйтелгән сүзләр безнең гаилә өчен генә түгел, күп кенә татарстанлыларга да житди мәсьәләгә әйләнде.

Көтмәгәндә, без – күп балалылар, льготалардан коры калдык. Республика законындагы "Адреслы социаль яклау" төзәтмәләре буенча, салым түләвенә өч тиен бурычың калган очракта да – бу яклау туктатылырга сәбәп була ала икән.

Әлеге тиенлек бурычны каплау өчен безгә 90 көн бирделәр. Күренеп тора, алдан уйланып эшләнгән хәйлә, чөнки интернет аша моны башкару мөмкин түгел. Күздә тотыла – салым инспекциясенә бару, чиратта тору һәм квитанция алу. Шул ук вакытта түрәләрнең үзләрендә оныту факторы: йә алар керем декларацияләрендә берничә банк счетларын күрсәтү хәтеренә килмәгән, йә чутка кермәгән кучемсез милекләрен ялгыш төшереп калдырганнар. Болардан бит шулай ук салым тотылырга тиеш! Ә менә җәзасы – бары тик шелтә белдерү һәм кисәтү генә. Безнең өчен салымнар, чынлап торып, чүп мәсьәлә булып тоелса да, авыр йөккә әйләнде.

Э. ГАБДРАХМАНОВА

КАЗАН

КЕШЕ КАЗАСЫ – ИЛ КАЗНАСЫ...

Хөрмәтле "Чаян"! "Мой Ритм", "Весна", "Яркий" һәм башка ваграк торак комплексларында "инвалидлар өчен генә" диган махсус билгеләнгән парковкалар бар. Гадәттә, андый мөмкинчелекләре чикләнгән машина йөртүчеләр анда бик аз.

Шул ук вакытта гади йөртүчеләргә башка урын табу кыен. Инде, аптырагач, льготалыларныкына куйсаң – эвакуаторлар карап кына тора, алалар да китәләр.

Аннан соң шуңа күңел кырыла, шул машина урыны бирелүдән башка инвалидларга бүтән уңай шартлар тудырылмаган. Юлны аркылы чыгу лифтлары эшләми, коляскалар өчен тротуарлар җайланмаган, пандуслар бөтен кибетләргә ясалмаган һәм дәваханәләргә дә юк. Җәмәгать транспортында да күтәргечләр кулланылмый. Аптырагач уйлап куясың, бу инвалидлар өчен билгеләнгән парковка урыннары – ширма гына түгелме икән дип, чынлыкта әлеге эшләр дәреслекне томалау булып санала һәм бюджетны штрафлар белән тулыландыруга чикләүсез мөмкинчелекләр генә тудыра.

И. ШАКИРОВ

КАЗАН



Александр АЛЁШИН




Василий АЛЕКСАНДРОВ



Хөрмәтле укучылар!

Безгә бераз онытыла башлаган «Чаян күнекмәсе»н искә төшерергә вакыт җитмәде микән? Баш миен эшләтеп, игътибар һәм күзәтүчәнлегебезне эшкә җигеп, җор телебезне чарлап алырга... Бу традицияне яңартып җибәрү өчен без редакциябез хезмәткәре Павел Староверовның фотосурәтен тәкъдим итәбез. Үтә тормышчан манзара, шулай бит?

Йә, рәсемне ничек атар идегез? Тәкъдимнәрегезне **chayan@bk.ru** адресы буенча җибәрегез. Көтеп калабыз.



Атаклы татар шагыйре, Советлар Союзы Герое, атаклы «Моабит дәфтәрләре» авторы Муса Җәлилнең тууына 115 ел булды. Аның батырлыгы һәм данлыклы тормыш юлы турында белмәгән кеше юктыр. Ләкин күп кенә шаян шигырьләрен аның Моабит төрмәсендә язуы бөтен кешегә дә билгеле түгелдер. Үзенең тормыш сөючәнлеген, юмор хисен Җәлил хәтта дошман зинданында үлем көтеп ятканда да югалтмаган.

Сугыш алды елларында Җәлилнең юмористик шигырьләре безнең журналда да еш кына басылып торган. Шагыйрь үзенең рухы белән чаянчыларга якын булган. Сезгә тәкъдим ителгән шигырьләр – моның ачык дәлиле.

БЕЗНЕҢ СӨЮ

(кыскартылып бирелә)

Безнең сөешү болай кызык кына
Булды бугай:
Кызыл вагонда,
Икебез дә волком членнары,
Бер съездга барган чагында
Син, өшегәч,
Килеп уртаклаштың
Минем җылы бәрән тунымны.
Менә шунда, каһәр,
Әллә ничек,
Бик үз булып миңа тоелдың.

Егерменче елның салкын кышы
Безнең сеңерләрне какшатты.
Син – җитез кыз,
Шунда, вагонда ук,
Бәрәңге дә пешереп ашаттың.
Бер тун белән төренеп,
Бер табактан
Ашый-ашый, сөенеп көлештек.
Мин оныттым инде,
Әллә шунда
Үбешмәдек,
Әллә үбештек!
Егерменче елның ачы җиле
Якаларга кереп өрә иде.
Син бик озак миңа коммунизм
Тормышының серен сөйләдең.
– Әле авыр,
Әле канлы еллар,
Канлы еллар, дидең, үтәбез,
Менә, дидең,
Шушы авырлыкны
Җиңеп бер көн аңар җитәрбез...

...Вагон ишеген каккан усал җил дә,
Котырынып очкан карлар да,
Көрәш белән тормыш төзү дәртен
Уяттылар безнең каннарда.

...Син съездда кулакларга каршы
Кызу-кызу речьләр сөйләдең,
Син ут идең,
Көрәш темпы белән
Бергә типте синең йөрәгең.

...Әй сөюшүебез безнең кызык кына
Булды бугай!
Кызыл вагонда,
Съезд бетеп,
Анда җиңеп чыккач,
Кире авылга кайткан чагында –
Син йончыган,
Арган гәүдәң белән
Минем кочагыма елыштың.
Мин оныттым –
Шунда әллә инде
Үбешмәдек,
Әллә үбештек?!..

...Утны, бозны бергә уртаклашкан
Әрсез көрәшчеләр идек без.
Шуңа күрә илне,
Бер-беребезне
Иң чын сөю белән сөйдек без.

БӘЛА

– Мим яратам бер хатынны,
Матурларның матуры.
Тик шунсы бар: ул матурым
Үзе бер ир хатыны.

– Гаҗәп түгел ансы, тик әйт:
Ул ирен яратамы?
Яратмаса, кыен түгел
Төзәтү бу хатаны.

– Ул яратмый бер дә ирен,
Җене белән бер күрә.
Утырып-утырып бу иренә
Чыкканына үкенә.

– Ә алайса ул иреннән
Аерылсын, әйт син аңа.
Гөрләтеп бер туй итәрсез,
Кояш чыгар сиңа да.

– Аһ, туганкай, рәхмәт сиңа,
Алтын синең бу сүзең,
Ләкин бөтен бәла шунда,
Аның ире –
мин үзем.

ГАШЫЙК ҺӘМ СЫЕР

Мин чәчәкләр җыйдым, сөеклемә
Бәйләм итеп бәйләп китердем.
Күрсен иркәм аның кулдалыгын
Йөрәгемнең, бәхтем, иркемнең.

Аһ, ни гарьлек, кызым чәчәкләрне
Тәрәзәдән тышка ыргыткан.
Ә аларны сыер ашап киткән...
Ничек түзим үлми хурлыктан!

Гашыйк сүзен сыер ишетте дә,
Гаҗәпләнеп, башын селкеде.
– Исем китә, – диде, – бу гашыйкка,
Карап торсаң, кеше шикелле!

Аңламыйча, ахмак, эшнең төбен,
Нигә шулай кыза, тузына?
Мин ашасам аның чәчәкләрен,
Сөт бирәм бит сөйгән кызына.

Минем сөттән аның йөзе алсу,
Минем сөттән – таза, сөйкемле,
Тәне йомшак, аның тешләре ак,
Яңа сауган сөтем шикелле...

Уйга калды гашыйк...
– Чын да, – диде, –
Ник тиргим мин бу сөтбикәне?
Ул бит көн дә, кырдан үлән җыеп,
Каймак белән сыйлый иркәмне!
Азык булсын гөлем сыерына,
Мин теләмим артык һичкемне!
Миңа шул да бәхет, әйдә, иркәм
Каймак итеп эчсен гыйшкымны...

Һәм юанды гашыйк...
Хәзер көн дә
Чәчәк җыеп чишмә буенда,
Кызга түгел, китереп чәчәкләрне
Ул ашата икән сыерга.

ИШЕК ТӨБЕНДӘ

Үтеп барам шулай урам буйлап,
Парадныйда күрәм: бер бала
Звонокка үрелә, буе җитми,
Аптырагач, карап уйлана.

Мин балага киләм:
– Әллә, – димен, –
Звонокка буең җитмиме?
– Җитми шул, – ди.
– Кая, үзем басыйм.
Бернеме, – дим, – әллә икеме?

– Биш, – ди. Басам.
Шуннан бала әйтә:
– Абзыкай, син нинди йөрәкле!
Әйдә качыйк хәзер, хуҗа чыкса,
Икебезгә дә бирер кирәкне!

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

“ЯШӘСЕН АМЕРИКА!”

Америка президенты Дональд Трамп иде әле ул чакта. Ак йортка чәчебашы тузган Мадонна килеп керде:

– Бетәбез, господин президент! – диде ул еш-еш сулап.

Трампның көндәлек эшләрен бетереп, хатыны Мелания белән сөтле чәй эчеп утырган чагы иде. Мадоннаның кыяфәте аны сагаерга мәҗбүр итте:

– Ни булды, чибәрем?..

– Нью-Йоркта узган “Үзгәреш җиле” турында ишеттегезме? Яңа афәт килә, господин президент! – Мадонна тәмам ярсыган иде. – Татар музыкасы чәчәк ата! Бөтен планета шуларны тыңлый! Безнең җырлар, безнең джаз, безнең мәдәният югалып бара! Бетәбез, господин президент! Бөтен американнар телефонда, бөтенесе татар клипларына мөкиббән!

– Әйе шул, – диде Трамп уйчан гына. – Мин дә уйлыйм бу хакта... Моны иртәгә Конгресста күтәрик без, бөтен Америкага чаң сугыйк. Демократлар да кушылсын, Британиядәге кардәшләребез дә! – ул йодрыгын һавада болгап алды. – Әйе-е-е, алар безне атом-төш коралы белән түгел, нәкъ менә шушының белән юк итәргә маташа. Идеологик корал – иң көчлесе!.. Яшәсен Америка!

Икенче көнне үк киңәшмәгә җыелдылар. Төрле яклап тәкъдимнәр ява башлады.

– Татарның иң көчле җырчыларын үзебезгә алырга кирәк! – диде госсекретарь Марк Помпео.

– Наил Тәбәнәковны күздә тотасыңмы? – дип сорадылар аннан.

– Әйе. Ямгуров белән Ленар Яшенне дә чакырыйк, коттедж, берәр миллион доллар зарплата бирик.

Шулчак Хәрби һава көчләре штабы башлыгы Дэвид Гольдфейн сүзгә кушылды:

– Сэр, эш монда җырчыларда гына түгел! Сез бер кешене онытасыз: текстлар авторын! Бөек шагыйрьне! Эстрада руле аның кулында, онытмагыз!

Ак йортта тынлык хасил булды. Һәммәсе дә сүзнең кем турында баруын чамалый иде.

– Айдар Минһаҗевның безгә килүе икеле, – диде Трамп тынлыкны бозып. – Аңа Татарстанда яхшы түлиләр...

Дүрт сәгать барган киңәшмәдән соң катгый карарга килделәр: кичекмәстән Россиягә шпионнар төркемен җибәрергә! Алар татар эстрадасына үтеп кереп, бөтен нәрсәне ачыкларга һәм уңышның серен белеп кайтырга тиеш!

– Аннары үзебездә дә шундый алымнарны кулланырбыз, – диде Трамп, тирләп чыккан сары чәчләрен артка таба сыпырып.

...Кара плащ, кара күзлек кигән өч шикле кеше Казан филармониясенә аяк басканда, анда бик матур җыр яңгырый, җырның “кило ярым прәннек” дигән сүзләре урамга ук ишетелә иде...

• • •

– ...Мөмкинме, господин президент?

Трамп вацабында актарына, Ангела Меркельдан килгән “җомга иртәсе мөбарәк булсын!” дигән картинканы карап маташа иде.

– Узыгыз! – диде ул башын күтәреп.

Кара плащ, кара күзлек кигән өч кеше Америка президенты каршына килеп басты.

– Барысын да ачыкладык! Бөтен мәгълүматлар бездә! – дип кесәсенә шапылдатты шпионнар төркеме башлыгы Джон Макфлай.

– Сөйлә, Джон!

Тегесе күзлеген салды һәм куен кесәсеннән мини-планшет тартып чыгарды:

– Татар эстрадасының бөек уңыш сере биш пунктан гыйбарәт, – дип башлады ул сүзен. – Беренчедән, клиплар! Әйе, әйе, аларда клиплар мощный! Ул клипларда автобус тукталышлары, каен агачлары, тракторлар...

– Нәрсә, бездә тракторлар беткәнме әллә? – дип кашын җыерды Трамп.

– Тракторлар бар анысы, тик менә салам түбәле өйләрне каян алыйк соң?..

– Дәвам ит! – дип боерды Трамп.

– Икенчедән, аларда реклама көчле!

– Ә бездә начармы?! – президент тәрәзәгә ымлады. – Әнә, “Кока-Кола” рекламасы, әнә, “Форд”ныкы!

– Түгел, аларныкы башка төрле реклама. Пиар дип атала. Аларда популяр булу өчен берәр гауга чыгарырга кирәк. Әйтик, җырымны урлагансың, дип, берәрсен судка бирергә, аягымны сындырдым дип инстаграм аша мескенләнергә, берәрсенең хатыны йә ире белән йокларга да шуны бөтен дөньяга сөйләп йөрергә...

– Фууу... – дип борынын җыерды Трамп.

– Фу шул менә!.. Өченчедән, аларда ялгыз җырлау модада түгел. Әгәр ир-егет җырчы икән, икенче көнне үк аның хатыны да җырлый башлый. Беләсезме, татар эстрадасында бүген ничә ирле-хатынлы җырчы бар? Биш йөз егерме сигез! Латыйповлар, Рамазановлар, Уразовлар...

– Яп!!!. – Трамп сүгенеп җибәрүен сизми калды.

– Дүртенчедән, господин президент, аларда депутатлар да җырлый.

– Кит аннан! – Трамп сикереп үк торды. – Не может быть!

– Валлаһи газыйм!

– Ник безнекеләр дә җырламый? Президент өстәлдәге кнопкага басты. – Марк, иртәгә үк проблеманы Конгресста күтәр, сенаторлар да җырлый башласын... Йә, бишенче пунктта нәрсә анда?

– Ниндидер сәер феномен, господин президент. Аларда бер исерек җырчы бар. Ул концерт куям дип афишасын элә һәм... – Джон уң кулының арты белән сул учына шапылдатты – Үзе килми!

– Ничек килми?.. Ә концерт?..

– Концертны дуслары куя. Халык канәгать. Тагын да кызыгы – бер елдан бу исерек җырчы тагын афиша элә, тагын үзе килми. Ә халык килә һәм тагын тегенең дусларының концертын карап кайтып китә. Шушы хәл инде ун ел буе бара... Феноменның хикмәте аңлашылмый...

– Әкәмә-ә-т! – Трамп торып басып, кабинет буйлап әрле-бирле йөренде. – Ничего! Ничего! – диде ул аннары ныклы бер карарга килеп. – Без бу “җилләр”гә нокта куярбыз! Үзгәртербез без аларны! Кирәк икән, Апаска да, кирәк икән, Буага да барып җитәрбез! Әмма борыннарына чиртәчәкбез татарларның. Президент кулын күкрәк турына куйды: “Яшәсен Америка!” – дип пышылдады. Башкалар аңа кушылды...



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 4 (1905) апрель 2021

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.


«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 02.04.2021 ел.
Тираж – 3407 Заказ Е-922

**Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.**

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Очрашканда кемнәр бер-берсенә мөлаемрак?
2. Ни өчен СССРда инженерлар яхшы булган?
3. Гаиләдә иминлекне саклау өчен ни кирәк?
4. Кар чистартуда иң алдынгы технология?
5. Гаиләдә хезмәт бүлешү нидән гыйбарәт?
6. Ни өчен элек балалар психологы кирәк булмаган?
7. Балаларның иң яхшы үсмер еллары?

ҖАВАПЛАР

1. Гөмбәчеләр. Һәркем белә: тирә-якта урман, очраткан һәрберсенең кулында пычак! 2. Балачакта балалар конструкторын һәм совет җиһазларын җыеп караганыгыз булдымы? 3. Мәхәббәт, сабырлык һәм ике компьютер. 4. Җылы һава торышы. 5. Ир чүп чыгара, хатын – миеңне... 6. Чөнки әти кеше берне тамызу белән аң чистара, кәеф җайга салына, тискәре энергияң бетә. 7. Сез инде аларны кулларыннан җитәкләп йөртмисез, алар да сезнең якка салпы салам кыстырмый.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 3 нче санында чаянвордның тикшерү сүзе – **«МИШӘ БУЙЛАРЫ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Г. ГАЙНЕТДИНОВА (Арча),
С. ГАЛИЕВА (Азнакай р-ны, Урманай ав.),
Н. НИКИТИНА (Чистай р-ны Чуаш Ялтаны ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).


Җиңүчебез – Арчадан
Г. ГАЙНЕТДИНОВА!



Белорус журналы «Вожык» рәссамнары
бездә кунакта













ВОЖЫК

